Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Советы Карары

25.02.2021 ел № 19

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында Кышлау авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 105 карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кышлау авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 105 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү:

**1.1. Нигезләмәнең 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 абзац өстәргә:**
- инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә»;
1.2. 3. 20 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:
«Әгәр гражданин җитди сәбәпләр (сәламәтлек, инвалидлык һ. б.) буенча гражданнар җыенында катнаша алмаса, гражданинның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аның яшәү урыны, аның гражданнар җыенында катнаша алмавы сәбәбе, шулай ук аның гражданнар җыенына чыгарыла торган үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсенә турыдан-туры мөнәсәбәте аның гаризасы нигезендә гражданнар җыенында исәпкә алына».
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Шакирова

Совет
Кшкловского
сельского
поселения
Кышлау
авыл җирлеге
Советы
ИНН 1610000620